КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 25 июнь г.Казань № 462

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет һәм балаларга транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет бирү тәртибен раслау турында» 2005 ел, 7 апрель, 161 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 28 декабрь, 628 нче; 2006 ел, 22 март, 117 нче; 2006 ел, 5 июль, 341 нче; 2006 ел, 2 октябрь, 490 нчы; 2007 ел, 21 март, 98 нче; 2007 ел, 17 декабрь, 726 нчы; 2008 ел, 5 июнь, 373 нче; 2008 ел, 14 ноябрь, 806 нчы; 2008 ел, 18 декабрь, 899 нчы; 2009 ел, 20 апрель, 239 нчы; 2009 ел, 28 декабрь, 897 нче; 2010 ел, 30 декабрь, 1135 нче; 2011 ел, 4 август, 633 нче; 2012 ел, 6 апрель, 279 нчы; 2012 ел, 17 сентябрь, 772 нче; 2013 ел, 19 гыйнвар, 22 нче; 2013 ел, 26 декабрь, 1062 нче; 2013 ел, 28 декабрь, 1074 нче; 2014 ел, 26 декабрь, 1036 нчы; 2015 ел, 30 ноябрь, 904 нче; 2016 ел, 27 декабрь, 1010 нчы; 2017 ел, 31 октябрь, 829 нчы; 2017 ел, 6 ноябрь, 844 нче; 2018 ел, 10 август, 655 нче; 2018 ел, 10 декабрь, 1108 нче; 2018 ел, 25 декабрь, 1228 нче; 2019 ел, 6 декабрь, 1111 нче, 2020 ел, 4 ноябрь, 990 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет һәм балаларга транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет бирү тәртибенә, 10 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән гражданнарга сатылган юл билетлары һәм балалар йөрү билетлары турында «Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасына Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртип һәм күләм нигезендә һәм «Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасы операторы билгеләгән форматлар нигезендә мәгълүмат кертүне тәэмин итә.».https://login.consultant.ru/link/?req=doc&base=RLAW363&n=151182&dst=100162

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Ташламалы транспорт кушымтасы булган электрон карталар һәм транспорт кушымтасы булган электрон карталар бирү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 2 июль, 574 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 6 ноябрь, 844 нче, 2019 ел, 19 июль, 604 нче, 2019 ел, 2 сентябрь, 745 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), 5 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«автоматлаштырылган система операторы белән берлектә «Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасына ташламалы транспорт кушымтасы булган электрон карталарның транспорт ресурсын тулыландыру турында мәгълүмат кертүне Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртип һәм күләм нигезендә һәм «Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасы операторы билгеләгән форматлар нигезендә тәэмин итәргә.».

Татарстан Республикасы<br>
Премьер-министры<br>
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин